РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«4» августа 2020 ел. г. Альметьевск № 86

«Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының норматив-хокукый актлар һәм норматив-хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 20 маендагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хокукый мониторинг тәртибендә, 2020 елның 21 июлендәге 02-01-25/2020 номерлы Әлмәт шәһәр прокуратурасы таләбен карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының норматив-хокукый актлар һәм норматив-хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 20 маендагы 12 номерлы карарына (Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендәге 53 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Закон белән каралган очракта, Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру процессында вазыйфаи зат норматив-хокукый акт проектын әзерләүче җирле үзидарә органнарыннан һәм вазыйфаи затларыннан мәгълүмат сората һәм ала. Сорау алынган материаллар һәм мәгълүмат вазыйфаи затка запрос алган вакыттан өч көннән дә артык булмаган вакытта бирелә.»;

19 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру вакыты кимендә биш көнгә.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту аппарат җитәкчесе Р.Е. Әфләтуновага йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Вәлиев

Исполнительный комитет города Альметьевска Республики Татарстан * Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 301